ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТИ АВТОНОМИЯЛЕ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ”

ПРОЕКТ ЭШЕ

# Тема: “5нче сыйныфта ФДГББС шартларында дәрес эшкәртмәсе”

Башкардылар: Гарифуллина Э.Т
Салахова Л.Т.
Гиниятуллина А.Ф.
Проектның фәнни җитәкчесе:
Мухарлямова Г.Н.
татар теле һәм әдәбияты
кафедрасы доценты

Казан, 2014

# Гарифуллина Энҗе Тәүфикъ кызы

Кайбыч муниципаль районы мәгариф бүлегенең милли мәгариф буенча методисты

# Салахова Ләйсән Таһир кызы

Буа муниципаль районы мәгариф бүлегенең милли мәгариф буенча методисты

# Гыйниятуллина Айсылу Фәгыйль кызы

Апас муниципаль районы мәгариф бүлегенең милли мәгариф буенча методисты

# Проектның максаты:

“Билгесез үткән заман хикәя фигыль” темасына

дәрес эшкәртмәсе төзү



# ПРОЕКТ БУРЫЧЛАРЫ:



1. Укучыларның белемен тикшерүгә, бәяләүгә карата ФДГББС таләпләрен өйрәнү;
2. Укучылар белемен тикшерү, бәяләүне дәрес эшкәртмәсенә кертү;
3. Дәрес эшкәртмәсен кулланып үткәрелгән дәреснең нәтиҗәлелеген бәяләү;
4. Эшкәртмәнең нәтиҗәлелегеннән чыгып, уку-укыту процессын кертү өчен төзәтмәләр өстәү.

# Проектның актуальлеге

Яңа мәгълүмати (информацион) белем бирү мохитенә күчү, шушы мохиткә хас педагогик мөмкинлекләрне, методларны, формаларны, җиһазларны һәм шулай ук укучылар өчен көтелгән нәтиҗәләрне тәэмин итәрлек төрле белем бирү эшчәнлекләрен өйрәнү һәм анализлауны күзаллый.

# Көтелгән нәтиҗәләр

Бүгенге көндә укытуның бигрәк тә кызыклы методларының берсе- интерактив методлар. Мондый методлар кулланып эшләгәндә дәрестә укучы актив катнашучы, белемне, мәгълуматны чыганаклардан үзе таба, ә укытучы бу очракта аңа юнәлеш бирә, чыганакларны тәкъдим итә. Укучы актив укытучы моның өчен шартлар тудыра.

# *Проектның тикшерү объекты*

Татар теле дәресендә рус төркемнәрендә белем алучы укучыларның билгесез үткән заман хикәя фигыльләрне куллануы, тәрҗемә итү өчен сүз байлыгы һәм сүзлекләрне кулланып, үз проектларын язу.

# Проектның фәнни яктан әһәмияте

Әлеге проект эшендә укытучы һәм укучы эшчәнлекләре компонентлар чылбыры: шәхескә кагылышлы УУГ, регулятив УУГ, академик УУГ, коммуникатив УУГ планлаштырылган. Проектның максатлары һәм бурычлары, максатка ирешү методлары, оештыру формалары, җиһазлау чаралары билгеләнгән. Эш барышында укучыларның шәхсән яклары, тема эчтәлеген аңлау, дәрескә әзерлек дәрәҗәләре күренә. Рус төркемнәрендә укучы укучылар белән эшләүче укытучыларга проектта күтәрелгән мәсьәләләргә күзәтү ясауның әһәмияте зур булыр дип саныйбыз.

## *Проектның практик яктан әһәмияте һәм яңалыгы*

Рус балалары белән эшләүче укытучыларга кулланма өчен материал була алуында. Проект алты этаптан: оештыру өлеше, актуальләштерү, яңа материалны аңлату, ныгыту, өй эше бирү, йомгаклаудан тора.

**ТЕМА:** *БИЛГЕСЕЗ ҮТКӘН ЗАМАН ХИКӘЯ ФИГЫЛЬ*

**ДӘРЕС ТӨРЕ:** *БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРНЕ АКТУАЛЬЛӘШТЕРҮ ДӘРЕСЕ.*

**МАКСАТ**

*1. БИЛГЕСЕЗ ҮТКӘН ЗАМАН ХИКӘЯ ФИГЫЛЬ КУШЫМЧАЛАРЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ, БИЛГЕЛЕ ҮТКӘН ЗАМАН ХИКӘЯ ФИГЫЛЬЛӘРНЕ КАБАТЛАУ;*

*2. ЛОГИК ФИКЕР ЙӨРТҮНЕ ҮСТЕРҮ, БИЛГЕСЕЗ ҮТКӘН ЗАМАН ХИКӘЯ ФИГЫЛЬНЕ СӨЙЛӘМДӘ АКТИВЛАШТЫРУ;*

*3. УКУЧЫЛАРНЫ ИҖАДИ СӨЙЛӘШҮГӘ ТАРТУ, ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮГӘ КЫЗЫКСЫНУЛАРЫН АРТТЫРУ.*

**БУРЫЧЛАР:**

1. *УКУ-УКЫТУ, ҺӨНӘРИ, ЭШ ТӨРЛӘРЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕН ӨЙРӘНҮ.*

*2. БУЛГАН СҮЗЛЕК БАЙЛЫГЫН, БИЛГЕСЕЗ ҮТКӘН ЗАМАН ХИКӘЯ ФИГЫЛЬНЕ КУЛЛАНЫП ҖӨМЛӘЛӘР ТӨЗЕРГӘ ӨЙРӘТҮ.*

*3. УКУЧЫЛАРНЫҢ ФИГЫЛЬЛӘРНЕ СӨЙЛӘМДӘ КУЛЛАНУНЫ АКТИВЛАШТЫРУ.*

# Көтелгән нәтиҗәләр.

**ШӘХЕСКӘ КАГЫЛЫШЛЫ НӘТИҖӘЛӘР:**

**-** ТУГАН ТЕЛЕБЕЗГӘ ХӨРМӘТ БЕЛӘН КАРАУ, ИХТИРАМ ХИСЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘҮ;

- ДӨРЕС СӨЙЛӘМ ФОРМАЛАШТЫРУ;
- ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗ БАЙЛЫГЫН ДӨРЕС КУЛЛАНУ.

**МЕТАПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ:**

**-** ТЕЛДӘН ҺӘМ ЯЗМА СӨЙЛӘМДӘ БИРЕЛГӘН МӘГЪЛҮМАТНЫ ДӨРЕС АҢЛАУ;

- ГАМӘЛДӘ АРАЛАШКАНДА ТЕЛНЕҢ ЛЕКСИК МӘГЪНӘСЕН ДӨРЕС АҢЛАП КУЛЛАНА БЕЛҮ КҮНЕКМӘЛӘРЕ БУЛДЫРУ.

**ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ:**

**-** ДӘРЕС МАТЕРИАЛЫН УҢЫШЛЫ ҮЗЛӘШТЕРГӘН БАЛАЛАР ТҮБӘНДӘГЕ БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРГӘ ИЯ БУЛЫРГА ТИЕШЛӘР:

- БИЛГЕСЕЗ ҮТКӘН ЗАМАН ХИКӘЯ ФИГЫЛЬ ТУРЫНДАГЫ БЕЛЕМНӘРНЕ ТОРМЫШТА УРЫНЛЫ КУЛЛАНУ;
- ҮЗ ФИКЕРЛӘРЕН ДӨРЕС ИТЕП ӘЙТӘ БЕЛҮ;
- ТӨРЛЕ ТИПТАГЫ СҮЗЛЕКЛӘР БЕЛӘН ЭШЛИ БЕЛҮ.

# ТӨП ӨЛЕШ

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|
| I Мотивлаштыру-ориентлаштыру этабы<br>1. Оештыру өлеше<br>2. Актуальләштерү<br>3. Уку мәсьәләсен кую | Исәнләшү. Эшне оештыру.<br>Төркемнәргә проблемалы сорау кую. Презентация күрсәтү. | Исәнләшү.<br>Җөмләләр төзиләр.<br>Бирелгән күнегүдән чыгып уку мәсьәләсен билгелиләр. | Коммуникатив: аралашуда катнашу. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|
| II Уку мәсьәләсен адымлап чишү.<br>Яңа теманы аңлату.<br>Сөйләмдә куллану.<br>Модельләштерү | Фонетик күнегү.<br><br>Аудиоязма тыңлау.<br><br>Яңа теманы аңлату.<br><br>Таблица белән эш итү.<br><br>Мультфильм күрсәтү | Төркемнәрдә аудиоязма тыңлыйлар һәм диктор сүзләрен кабатлыйлар.<br><br>Һәр төркем җөмлә төзи.<br><br>Схема һәм таблица белән эшлиләр.<br><br>Сорауларга җавап.<br>Мультфильмнан бер өзек карап, билгеле үткән заман һәм билгесез үткән заман фигыльләрен табалар | Регулятив: планлаштыру, контроль, коррекция<br><br>Коммуникатив: сорау куя һәм адреслый белү, фикереңне башкаларга җиткерү<br><br>танып-белү: уку мәсьәләсен чишү, модельләштерү, белем алу чыганакларыннан файдалана белү |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
| --- | --- | --- | --- |
| III Рефлексив бәяләү этабы<br>Үзбәя.<br>Рефлексив кабатлау.<br>Өй эше бирү. | Онлайн тестирование үткәрү.<br>Укучылар төркемнәре белән әңгәмә | Тест биремнәрен үтәү.<br>Һәр төркемнең чыгышы | Коммуникатив: коммуникатив мәсьәләләрне чишүдә катнашу |

# ПРОЕКТ ЭШЕН ЙОМГАКЛАУ

- Бу заманча дәрес эшкәртмәсе проектында балаларның аралашу күнекмәләрен камилләштерү, диалогик һәм монологик сөйләмне дөрес формалаштыру, сөйләмдә сүзләрне урынлы куллануга ирешү, сөйләм телен камилләштерү һәм морфологиянең кайбер өлешләренә фәнни якын килү юллары бирелә. Эш түбәндәге тәртиптә барса, балалар регулятив, коммуникатив, танып-белү, шәхескә кагылышлы универсаль гамәлләрен үзләштерәчәк. Проект эшен башкару барышында без фәнни-методик әдәбият, интернет – ресурслар һәм вакытлы матбугат материалларын кулландык.

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ИНТЕРНЕТ РЕСУРСЛАР


- Асмолова. – М. : Просвещение, 2010. – (Стандарты второго поколения). Камзеева, Е.Е. Формирование и развитие ИКТ-компетентности педагога в условиях введения и реализации ФГОС // Методист. - 2012. - № 4. - С.35.
- Әбдрәхимова Я.Х. Татар теленнән бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре. - К., 2005 .
- Әбдрәхимова Я.Х. Татар теленнән дидактик материаллар–К., 2004.
- Вәлиева Ф.С. Укучыларның язу һәм сөйләм телен үстерү мәсьәләләре –К., 1976.
- Гузенко, Ю.В. Реализация программы формирования УУД в образовательном процессе // Методист. - 2011. - № 9. - С. 62-64.
- Трофимова С.М. Татар теле һәм әдәбияты укытучысына (Рус һәм татар мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен методик ярдәмлек).Казан: Яңалиф, 2005.
- Тумашева Д.Г., Вәлиуллина З.М. 5 нче класста татар теле дәресләре: Укытучылар өчен кулланма.
- Федоренко Л.Г. Мәктәп шартларында психологик сәламәтлек (Психологическое здоровье в условиях школы.) СПб.:КАРО, 2003. – 208с.
- Формирование универсальных учебных действий в основной школе: от действия к мысли : система заданий : пособие для учителя / под ред. А.Г.
- Хәйдарова Р.З. “Татар теле” 5 сыйныф, Казан “Татарстан китап нәшрияты” 2011.
- Хәйдарова Р.З., Л.Ә.Гыйниятуллина. Татар теле дәресләре. 5сыйныф. Рус телендә сөйләшүче балалар белән эшләүче укытучылар өчен кулланма.
- ХарисовФ.Ф., Харисова Ч.М. Рус мәктәпләрендә татар балаларына ана теле укыту. Укытучылар өчен методик кулланма. 5 сыйныф. Казан,2000.

Кулланылган интернет ресурслар:

- HTTPS://EDU.TATAR.RU
- HTTP://WWW.LANGUAGES-STUDY.COM
- HTTP://TATAR.COM.RU/
- HTTP://BELEM.RU/

# Кушымта 1.

Таблица. Билгесез үткән заман

| Нинди авазга беткән | Боерык фигыль | Кушымчалар | Билгесез үткән заман | Мисаллар |
|---|---|---|---|---|
| яңгырау тартыкка | бар<br>кил | -ган<br>-гән | барган<br>килгән | Марат барган<br>Ул килгән |
| саңгырау тартыкка | кайт<br>кит | -кан<br>-кит | кайткан<br>киткән | Әти кайткан<br>Ул киткән |
| сузык авазга | аша<br>сөйлә | -ган<br>-гән | ашаган<br>сөйләгән | Ул ашаган<br>Ул сөйләгән |

# КУШЫМТА 2.

-  Электрон карточкаларда бирем язылган: “Диалогны тулыландырыгыз”
- - ...........?
- - Миша Мәскәүдән кайткан.
- - Миша Мәскәүдә кая барган?

# ҮЗБӘЯ.



Миңа бар да аңлашыла!



Уйларга була!



Өйрәнергә кирәк!

*Игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт!*